РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422126, с.Сардек-Баш , Ул.Центральная , д.45 Тел./факс: (884364) 25-0-43 e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru,

# КАРАР

2023 елның 24 июле №15

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 январендагы 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сәрдекбаш Советы карар бирде:

1. Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 январендагы 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә (Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 36 нчы номерлы, 2018 елның 22 июнендәге15 нче номерлы , 2019 елның 26 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августендагы 16 нчы номерлы, 2021 елның 09 июнендәге 12 нче номерлы, 2021 елның 23 ноябрендәге 28 нче номерлы, 2022 елның 28 январендагы 1 нче номерлы, 2022 елның 09 сентябрендәге 23 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 18.1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18.1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен», «блокланган торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше», «блокланган торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 2 өлеше 2 пунктында («Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциядә) күрсәтелгән блокланган торак йортларда торак биналар буларак блоклар турында (аларның атамасына яки рөхсәт ителгән куллану төренә карамастан) мәгълүмат кертелсә һәм мондый блокларга хокуклар теркәлсә, мондый блоклар урнашкан «блокланган торак төзелеше» рөхсәт ителгән куллану төре булган җир кишәрлекләре өчен чик үлчәмнәр билгеләнми.

1.2. 27 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«5.1) әгәр мондый килешү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 40.1 статьясында каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү;»

1.3. 28 статьяның 7 өлешендә «башкарма документацияне алып бару составы һәм тәртибе» дигән сүзләрне алып ташларга;

1.4. 35 нче статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналар

1. Торак зоналар күп катлы торак йортлар, кече һәм урта катлы торак йортлар, шәхси торак йортлар төзү өчен билгеләнгән.

2. Рөхсәт ителгән төп кулланылыш объектлары территориянең ким дигәндә 60 % ын биләргә тиеш. Территориянең 40 % ына кадәр рөхсәт ителгән куллануның төп төрләренә карата ярдәмче объектларны урнаштыру өчен кулланырга рөхсәт ителә.

Ж-1. Шәхси торак йортлар төзелеше зонасы

Ж-1 шәхси торак йортлар төзү зонасы йорт яны җир участоклары белән яки аларсыз, җирле әһәмияттәге хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән аерым торучы һәм блокланган шәхси торак йортлардан (коттеджлардан) торак районнар формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

Шәхси торак төзелеше зонасы түбәндәгеләрне урнаштыру өчен билгеләнгән:
- шәхси торак төзелеше һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән йорт яны җир кишәрлекләре белән аерым торган торак йортлар;
- блокланган торак йортлар;
- аз катлы күп фатирлы торак йортлар (дүрт катка кадәр, шул исәптән мансардалы).

Торак зоналарда физик һәм юридик затларны түбәндәге коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүче биналарны һәм корылмаларны урнаштыру рөхсәт ителә: су, җылылык, электр, газ белән тәэмин итү, канализация агынтыларын чыгару, күчемсез милек объектларын (котельняларны, су алу башняларын, чистарту корылмаларын, насос станцияләрен, суүткәргечләрне, электр тапшыру линияләрен, трансформатор подстанцияләрен, газ үткәргечләрен, элемтә линияләре, телефон станцияләрен, канализацияләр, туктальшшлар, урып-җыю һәм авария техникасына хезмәт күрсәтү өчен гаражлар һәм мастерскойларны, кар җыю һәм эретү өчен корылмаларны) чистарту һәм җыештыру.

Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре:

- аерым торучы яки торак йортларга терәп салынган гаражлар яки машина кую өчен ачык урыннар: шәхси кишәрлек өчен 2 машина урыны;
- кечкенә үлчәмле судноларны саклау өчен гаражлар;
- хуҗалык, йорт яны корылмалары;
агач бакчалары, яшелчә бакчалары, алгы бакчалар;
- теплицалар, оранжереялар;
- гомуми мәйданы 150 кв. м. дан артмаган беренче кирәкле товарлар кибетләре;
- даруханәләр;
- гомуми мәйданы 600 кв. метрдан артмаган амбулатор-сырхауханә учреждениеләре;
- су саклау өчен махсус резервуарлар;
- су алу өчен скважиналар, шәхси коелар (җир асты суларының саклану дәрәҗәсенә карап, кимендә 30 һәм 50 м аралыкта санитар саклау зонасын оештыру шарты белән);
- шәхси бассейннар;
- шәхси мунчалар, сауналар, ишегалды бәдрәфләре;
- янгыннан саклану объектлары (гидрантлар, резервуарлар, янгынга каршы сулыклар);
- ашлама саклау мәйданчыклары, тирес мәйданчыклары, чокырлары яки тартмалары;
- чүп җыю мәйданчыклары.

Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре:

- биеклеге 4 каттан артмаган, фатир яны кишәрлекләре булган яки аларсыз аз катлы күп фатирлы торак йортлар;
- балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- кер юу һәм химик чистарту кабул итү пунктлары;
- күп дигәндә 20 урынлык кунакханәләр;
- вакытлыча сәүдә объектлары;
- офислар, банк бүлекчәләре;
- клублар (мәдәният йортлары);
- китапханәләр;
- дини объектлар;
- фельдшер-акушерлык пунктлары, шул исәптән модульле;
- терлек һәм кош-корт асрау өчен корылмалар (күршеләр белән дустанә мөнәсәбәтләр сакланса);
- хайваннарны даими асрамый торган ветеринария лечебницалары;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- спорт заллары, рекреация заллары;
- эш вакыты чикләнгән күп максатлы һәм махсус куллану клублары;
- полиция бүлекләре, участок пунктлары;
- элемтә бүлекчәләре;
- торак-эксплуатация оешмалары һәм авария-диспетчерлык хезмәтләре;
- мәдәни, хезмәт күрсәтү һәм коммерция куллану объектлары алдындагы машина кую урыннары.
- кәрәзле, радиорелелы, спутник элемтәсе антенналары;
- вак көнкүреш ремонты (аяк киеме, кием, кулчатырлар, сәгатьләр һ. б. ремонтлау) буенча кабул итү пунктлары һәм остаханәләр;
- 100 кв. м кадәр тегү ательелары һәм остаханәләре;
- чәчтарашханә, косметика салоны, матурлык салоны;
- үз ихтыяҗлары өчен гаражлар;
- автомобильләрне ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән остаханәләр;
- автомобиль юу урыннары;
- кибетләр;
- һәйкәлләр һәм истәлекле билгеләр.

Җир кишәрлекләренең зурлыгы һәм рөхсәт ителгән төзелеш параметрларының чик кыйммәтләре әлеге бүлеккә аларны эшкәртүгә карап кертеләчәк. Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларын эшләгәнче, аларны билгеләү җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планының тиешле бүлеге белән башкарыла.

Ж-1П. Перспективалы торак төзелеше зонасы

Перспективалы торак төзелеш зонасы Кукмара муниципаль районы һәм Сәрдекбаш авыл җирлегенең территориаль планлаштыру документларына

ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән аерым торган шәхси йортлар белән планлаштырылган төзелеш өчен бүлеп бирелгән.

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре, рөхсәт ителгән файдалануның чик параметрлары, Ж-1П зонасы өчен җир кишәрлекләрен төзүгә таләпләр җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләренә, Ж-1 зонасы өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен төзүгә чик параметрларына һәм таләпләренә туры килә.»

б) 2 нче «Шәһәр төзелеше регламентлары. Иҗтимагый-эшлекле зоналар» бүлегендә «Күчемсез милекне рөхсәт ителгән куллануның төп төрләре» бүлекчәсен түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«дини кулланыштагы биналарны һәм корылмаларны урнаштыру;

- дини йолалар һәм тантаналар башкару өчен билгеләнгән биналар һәм корылмалар (чиркәүләр, соборлар, гыйбадәтханәләр, часовнялар, мәчетләр, гыйбадәт йортлары, синагогалар) урнаштыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: Нәбиев И.М.

ОГРН 1021607752858
ИНН 1623001854